| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет<br>Каенлынского сельского поселения<br>Нижнекамского муниципального района<br>423553, Нижнекамский район,<br>с. Каенлы, ул. Школьная, 8 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Түбән Кама муниципаль районы<br>Каенлы авыл жирлеге<br>Советы<br>423553, Түбән Кама районы,<br>Каенлы авылы, Мәктәп урамы, 8 |

тел./факс (8555) 44-98-35, электронный адрес: Prostinskoe.sp@tatar.ru,
сайт: www.prostinskoe-sp.ru


РЕШЕНИЕ КАРАР

11.06.2024 ел № 6

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Түбән Кама муниципаль районының «Каенлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Каенлы авыл җирлеге Советы карар бирә:

Аерым салым түләүчеләр өчен исәпләнүче 2024 елның 1 гыйнварына җирле салымнар суммалары өлешендә бурыч түләүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр билгеләргә:

1) варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирас кабул итмәгән очракта үлгән яисә вафат булган физик затларның бурычы булу;

2) оешмалар яисә индивидуаль эшкуарлар тарафыннан 2024 елның 1 гыйнварына кадәр юкка чыгарылган җирле салымнар буенча исәпләнелә торган бурыч булу;

3) физик затларның Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Р.Р.Гарипов